| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020 Казан ш. № 451-87/тэ-2020

Кулланучыларга «Саба күп тармаклы житештерү торак-коммуналь хуҗалык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 № 5-66/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021-2023 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2021-2023 елларга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Саба күп тармаклы житештерү торак-коммуналь хуҗалык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен тарифлар билгеләү хакында» 05.12.2018 № 5-66/тэ карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 5-37/тэ карары керткән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.12.2018 № 5-66/тэ
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2020 № 451-87/тэ-2020
карары редакциясендә)

## «Саба күп тармаклы җитештерү торак-коммуналь хуҗалык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләштерүче пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5тән 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Саба муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Саба торак-коммуналь хуҗалыгының күптармаклы җитештерү предприятиесе» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1905,60 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1961,57 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1961,57 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1979,47 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1979,47 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 2018,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1969,84 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2039,89 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 2039,89 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 2081,72 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге